**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

№9 2019 елның 4 июле

Акбаш авылы

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең законнарга һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларга үзгәрешләр мониторингын үткәрү турында Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү буенча эшен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы кушымтадагы Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә htt://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Акбаш авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Г.Ф. Хаҗиева

Акбаш авыл җирлеге
Советы карары белән расланды
4 июль 2019 ел №9

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Закондагы үзгәрешләргә һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый норматив актларына мониторинг үткәрү (алга таба – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) муниципаль актларның кабул ителешен (игълан ителешен), үзгәртелешен яки көчен югалткан (кире кагылган) дип саналышын тәэмин итү өчен җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләре чикләрендә магълүматлар җыю, аларны гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлеген күздә тота.

2. Мониторинг Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3.Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары мониторинг үткәргәндә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге белән хезмәттәшлек итәләр.

4. Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары булып тора :

федераль һәм республика законнарына туры китерү максатларында, муниципаль актларны кабул ителүе, үзгәртелүе һәм аларның үз көчләрен югалткан дип саналуы ихтыяҗы булуын ачыклау;

муниципаль актларда коллизияләрне, каршылыкларны, кимчелекләрне бетерү, хокукый җайга салуда кабатлаулардан арыну;

җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;

муниципаль актларда коррупциячел факторларны ачыклау;

гамәлдән чыккан (актуальлеген югалткан) яисә кулланылмаган муниципаль актларны яисә аларның аерым нигезләмәләрен (нормаларын) ачыклау;

хокук куллану нәтиҗәлелеген арттыру; муниципаль актларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген киметүче факторларны ачыклау;

муниципаль актларның үтәлешенә җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләре тарафыннан контрольне гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;

норматив актлар чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү .

6. Мониторинг үз эченә түбәндәгеләрне җыюны, гомумиләштерүне, анализлауны һәм үзгәрешләрне бәяләүне ала:

федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка закон актларын;

Россия Федерациясе Президенты указларын, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын, федераль дәрәҗәдәге башка законга кагылышлы норматив хокукый актларны;

Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы  Акбаш авыл җирлеге Уставын,  муниципаль актларны .

7. Мониторинг үткәрүнең нигезләре булып тора:

федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертү;

муниципаль актларны хокукый җайга салуны аерым өлкәләрдә куллануны анализлау;

прокуратура органнары мәгълүматы;

массакүләм мәгълүмат чараларының  муниципаль актларны камилләштерү мөһимлеге яки кимчелекләре турында мәгълүматы;

муниципаль актларның камил булмавы хакында гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклау һәм башка оешмаларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре, шул исәптән түбүндәгеләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләр:

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелгән муниципаль актларга карата үткәрелгән Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан үткәрелгән хокукый экспертиза бәяләмәсе;

билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле затлар тарафыннан әзерләнгән муниципаль актларга коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәсе;

җирле үзидарә органнары үткәрә торган конференцияләрнең, семинарларның, ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышуларның һәм башка чараларның йомгаклау документлары.

## II. Мониторинг үткәрү тәртибе

8. Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары үз компетенцияләренә кагылган мәсьәләләр буенча  әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән үзара бәйләнештә мониторинг үткәрәләр.

Мониторинг үткәрү максатларында эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат соратып алынырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре, Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсе өйрәнелергә, башка эш формалары кулланылырга мөмкин.

9. Мониторинг түбәндәгеләрне анализлау аша башкарыла:

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актларны;

федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларны дәгъвалау эшләре буенча суд актларын (суд практикасы) ;

прокурор җавабы актларын.

10. Мониторингны гамәлгә ашыру, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын анализлау, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча үткәрелгән норматив хокукый актлар чыгару эше нәтиҗәләрен теркәү максатларында, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару

тәртибе турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары файдаланыла.

11. Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү өчен түбәндәгеләрне тәэмин иткән мәгълүмат системаларының автоматлаштырылган сервислары кулланыла (контрактлар, аларның операторлары белән килешүләр төзүгә бәйле күрсәтелгән мөмкинлекләр булганда):

"Гарант" мәгълүмат системасында контрольга куелган закон һәм башка норматив хокукый актларга үзгәрешләр турында мәгълүмат керү;

"Гарант" мәгълүмат системасына хокукый җайга салуның тиешле өлкәләре буенча яңалыклар мәгълүматы керү;

«Кодекс» мәгълүмат компаниясенең «Региональ закончалык аналитигы" автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан мәгълүмат керүе.

Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү максатларында башка мәгълүмат системалары сервислары файдаланыла ала.

12. Муниципаль хокукый актларны кабул итүне (бастырып чыгаруны) үзгәртелешен яки көчен югалткан (гамәлдән чыгаруны) дип саналышын тәэмин итү, әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән беррәттән, муниципаль актларның куллану практикасы турында мәгълүмат түбәндәге критерийлар буенча гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларының, ирекләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше;

муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару) зарурлыгы билгеләнгән зуррак юридик көчкә ия норматив хокукый актлар булуы;

муниципаль акт чыгарганда, җирле үзидарә органы үз компетенциясе чикләренең үтәлеше;

муниципаль актта коррупциячел факторлар булуы;

иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуның тулылыгы;

хокук нормаларында каршылыклар;

юридик-техник характердагы хаталар булуы;

муниципаль актны кулланганда муниципаль акт нигезләмәләренең мәгънәсен бозу;

муниципаль хокукый актны кулланганда, хокуксыз яисә нигезсез карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау) ;

норматив хокукый актларны куллану тәҗрибәсе булу;

норматив хокукый актларны куллануда бертөрдәге тәҗрибә булмавы;

муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризалар булу (саны) һәм аларның эчтәлеге;

муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында закон көченә кергән суд актлары булу (саны) һәм аларны кабул итү нигезләре.

13. Мониторинг йомгаклары буенча федераль һәм республика законнарында үзгәрешләр муниципаль актларга үзгәрешләр кертүне таләп иткән очракта җирле үзидарә органнары тарафыннан:

муниципаль актка үзгәрешләр кертү турында, муниципаль актның үз көчен югалтуын тану турында, яңа муниципаль акт кабул итү турында тиешле муниципаль актлар проектлары эшләнә;

муниципаль актларны зуррак юридик көчкә ия булган актлар белән тәңгәлләштерүгә юнәлдерелгән башка чаралар күрелә.

14. Муниципаль актларны үзгәртү ихтыяҗын тудыручы федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертелгән очракта, мониторинг федераль яки республика актын чыгарганнан соң, 30 көн эчендә үткәрелә.

Мониторинг үткәрүгә нигез булып гражданнарның, юридик затларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре, шулай ук “Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль закон белән билгеләнгән срокларда каралырга тиешле прокурор күзәтчелеге актларыннан тыш башка прокуратура мәгълүматы торганда, мониторинг алар кергәннән соң, 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла. Әлеге очракларда мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүче затка хәбәр ителә.

Федераль һәм республика законнары актларының ерак перспективада үз көченә керә торган үзгәрешләре ачыкланган очракта, җирле үзидарә

органнарының норматив-хокукый актлар чыгару эшчәнлеге планнарына тиешле төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

### III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Муниципаль акт проектын эшләү һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт кабул итү, әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, федераль һәм (яисә) республика законнарының тиешле акты үзгәртелгән көннән соң, ике айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

16. Мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында хисап аеннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, мониторинг нәтиҗәләре турында хисап тота.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүматны;

мониторинг үткәрү башкаручылары турында мәгълүматны;

мониторинг үткәрү чоры турында мәгълүматны;

хокукый җайга салу предметының кыскача характеристикасын, мониторинг үткәрү нигезләрен.

16.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

хокукый җайга салуның ачыкланган проблемалары турында мәгълүматны;

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яки) яңа муниципаль актларны кабул итү, юкка чыгару зарурлыгы турында тәкъдимнәрне;

тиешле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәрне.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча кабат кабул ителгән муниципаль актлар, законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрелә. Әлеге регистрга кертү өчен мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган һәм анда кертелмәгән муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча норматив документлар чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19. Мониторинг үткәрү һәм хокукый документлар чыгару эшчәнлеге өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру, шулай ук җирле үзидарә органнары карамагында булган тиешле хокукый җайга салу өлкәсендә муниципаль актларны федераль һәм республика законнарына туры китерү өчен шәхси (шул исәптән дисциплинар) җаваплылыкта булалар.

20. Тискәре нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлләр (гамәл кылмау) өчен законнар нигезендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җаваплы була.